| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 24 январе Багай ав. № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең 2019-2029 елларга транспорт инфраструктурасын комплексլы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасын үстерүне тәэмин итү, аның иминлеге дәрәҗәсен күтәрү максатыннан, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Багай авыл жирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 сентябрендәге 11 номерлы карары белән расланган «2019-2029 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортында 8 нче юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 8 | Финанслау чыганаклары | Программа буенча финанслауның гомуми күләме муниципаль берәмлек бюджеты акчаларыннан 7 286,1 млн сум тәшкил итә. |

| | | |
|---|---|---|
| | | Искәрмә: Финанслау күләме фаразланган характерда һәм җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш |

муниципаль программага 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

2 нче таблица

| Чаралар исеме | Объектның урнашу урыны | Вакыты, период | Кирәкле финанслау |
|---|---|---|---|
| Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының техник документларындагы мәгълүматларны актуальләштерү, бүлеп бирелгән полосаларны билгеләү | Багай ав.<br>Салтыган ав.<br>Арыслан ав.<br>Кодыбирде ав. | 2020-2029 еллар | |
| Җирлек урамнарында һәм автомобиль юлларында барлык инженерлык корылмаларының техник торышын бәяләп инвентарьлаштыру | Багай ав.<br>Салтыган ав.<br>Арыслан ав.<br>Кодыбирде ав. | 2020 | 7,36 |
| | | 2021 | 7,36 |
| | | 2022 | 7,36 |
| | | 2023 | 7,36 |
| | | 2024 | 7,36 |
| | | 2025-2029 | 36,8 |
| Юллар өслеген үзгәртүне исәпкә алып, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары исемлегенә үзгәрешләр кертү | Багай ав.<br>Салтыган ав.<br>Арыслан ав.<br>Кодыбирде ав. | 2020-2029 еллар | |
| Территорияләрне планлаштыру буенча документацияне эшләү белән бергә юл хәрәкәте иминлеге буенча комплекслы чаралар комплексын эшләү һәм тормышка ашыру | Багай ав.<br>Салтыган ав.<br>Арыслан ав.<br>Кодыбирде ав. | 2020-2029 еллар | |
| Торак пунктларның урамнарына реконструкция, ремонт ясау, каты өслек урнаштыру | Багай ав.<br>Салтыган ав.<br>Арыслан ав.<br>Кодыбирде ав. | 2020 | 721,25 |
| | | 2021 | 721,25 |
| | | 2022 | 721,25 |
| | | 2023 | 721,25 |
| | | 2024 | 721,25 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 2025-2029 | 3 606,25 |
| БАРЫСЫ: | | | 7 286,1 |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Багай авыл җирлеге башлыгы** **Р. Ф. Кузнецова**